**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2024 ел** **№2**

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләрдә көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә , хәрби хезмәт үтү турында контракт төзеп һәм махсус хәрби операциягә җибәрелде, 2 төркем инвалидларга бер тапкыр бирелә торган түләүне 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм алыштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистартканда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү, трактор йөртүченең үләнне механикалаштырып чаптыру буенча хезмәтләре өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82(чапкыч) өчен асмалы җайланмалар сатып алу, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы Сарлы
авыл җирлеге башлыгы И.М.Камалетдинов